Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 февраль 2022 ел № 124

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман, Аппак, Багряж-Никольский, Бишмунча, Борискино, Бута, Югары Мактама, Елховой, Ерсубайкино, Кузайкино, Урман-Кәләй, Мәмәт, Яңа Кәшер, Яңа Троицкий, Сәрән, Иске Суркино, Сөләй, Тайсуган, Ямаши, Ямаш авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясы 6 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман, Аппак, Багряж-Никольский, Бишмунча, Борискино, Бута, Югары Мактама, Елховой, Ерсубайкино, Кузайкино, Урман-Кәләй, Мәмәт, Яңа Кәшер, Яңа Троицкий, Сәрән, Иске Суркино, Сөләй, Тайсуган, Ямаши, Ямаш авыл җирлекләре территориясендә җирлекләр территорияләреннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмау, федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы һәм Әлмәт муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе, территориаль планлаштыру схемаларын раслау таләп ителми,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман, Аппак, Багряж-Никольский, Бишмунча, Борискино, Бута, Югары Мактама, Елховой, Ерсубайкино, Кузайкино, Урман-Кәләй, Мәмәт, Яңа Кәшер, Яңа Троицкий, Сәрән, Иске Суркино, Сөләй, Тайсуган, Ямаши, Ямаш авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмауны расларга.

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник»» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Мингазов И.М.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов